**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 167-28 «01» февраль 2024 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә хакында» 2023 елның 14 декабрендәге 161-26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-Ф номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1.«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә хакында» 2023 елның 14 декабрендәге 161-26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру ысуллары» 6 бүлегенең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында: 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла:
- унитар предприятиене акционер җәмгыятькә үзгәртеп кору;
- унитар предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртеп кору;
- конкурста дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сату;
- аукционда муниципаль мөлкәтне сату;

- махсуслаштырылган аукционда акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен сату;
- гавами тәкъдим ярдәмендә муниципаль мөлкәтне сату;
- бәяләрне игълан итмичә муниципаль мөлкәт сату;
- акционер җәмгыятьләрнең устав капиталларына кертем буларак муниципаль мөлкәт кертү;
- ышаныч белән идарә итү нәтиҗәләре буенча акционер җәмгыять акцияләрен сату.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин